**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**25 ноябрь 2022 ел** **№ 58**

**2019 нчы елның 22 нче ноябрендәге Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 148 нче номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2019 нчы елның 22 нче ноябрендәге 148 нче номерлы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»гы карарына (2020 нче елның 15 нче маендагы 164 нче номерлы, 2022 нче елның 25 нче ноябрендәге 57 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә), 7 нче пунктның 7.1 подпунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

« - 2022 нче елның 21 нче сентябрендәге 647 нче номерлы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»гы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Бу карар 2021 нче елның салым чорына җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов